РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 30 » 11 2023 г. №1939

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының мәгълүмат-методика үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2007 елның 26 сентябрендәге 142 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2023 елның 7 июлендә Татарстан Республикасы буенча 18 нче Федераль салым хезмәтенең районара инспекциясе тарафыннан «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының мәгълүмати-методик үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе бетерелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының мәгълүмат-методика үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының

2007 елның 26 сентябрендәге 142 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе С.П. Самонина